ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 1500 « 23 » 11 2016 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2016 елның 14 октябрендәге
1277 номерлы карарына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында

Мамадыш районы прокуратурасының муниципаль норматив хокукый акт проектына карата 2016 елның 23 сентябрендәге бәяләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 14 октябрендәге «2016/2017 елның кышкы чорында Мамадыш муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында» 1277 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

- карарның 2,3,4,5,6,7 пунктларында җөмлә башында «Тәкъдим итәргә» сүзтезмәсен өстәргә;
- Карарга кушымтаның («Буран» планы) 1.2 пунктында икенче абзацны төшереп калдырырга;
- Карарга кушымтаның («Буран» планы) 1.4 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Э.Фәттахов